ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.01. 2019 ел. Баулы № 5

Баулы муниципаль районы территориясендә авиация эшләрен башкаруга, парашют белән сикерүгә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз очу аппаратлары очышларына, Баулы муниципаль районы территориясеннән бәйләү аэростатларының күтәрелешенә, Баулы муниципаль районы чикләрендә урнашкан, алар турында мәгълүмат аэронавигация мәгълүмат документларында бастырып чыгарылмаган мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 декабрендә кабул ителгән 509нчы номерлы карары (25.05.2018 205нче санлы карар белән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән) белән расланган Административ регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2018 елның 27 июлендә кабул ителгән ( 2018.18.04 ред-н) 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы территориясендә авиация эшләрен башкаруга, парашют белән сикерүгә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз очу аппаратлары очышларына, Баулы муниципаль районы территориясеннән бәйләү аэростатларының күтәрелешенә, Баулы муниципаль районы чикләрендә урнашкан, алар турында мәгълүмат

аэронавигация мәгълүмат документларында бастырып чыгарылмаган мәйданчыкларга төшүгә (очып китүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 декабрендә кабул ителгән 509нчы номерлы карары (25.05.2018 205нче санлы карар белән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән) белән расланган Административ регламентка түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» дигән II кисәктә:

2.5 пунктта: Искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Искәрмә: әлеге пунктта күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан, планлаштырылган авиация эшчәнлеге төренә бәйле рәвештә, расланган күчермәләр рәвешендә (гаризалардан тыш) тапшырыла.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа кушымта булган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яисә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиле тарафыннан;

- тапшыру турында уведомление белән почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»;

V бүлек. «Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибен» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешенең 16 статьясында каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү, комплекслы запросны теркәү вакытын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу.

Әлеге очрака мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү түбәндәге шартларда мөмкин: КФҮгә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1.3 бүлегенең 16 статьясында билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнсә;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районының норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны бирү, эш башкару таләбе;

4) мөрәҗәгать итүчедә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Баулы муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту.

Әлеге очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү түбәндәге шартларда мөмкин: КФҮгә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнсә;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү сорау;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренец, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1.1 өлешендәге 16 статьясында каралган оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

Әлеге өчракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренец карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү түбәндәге шартларда мөмкин: КФҮгә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнсә;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенец башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору.

Әлеге өчракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү түбәндәге шартларда мөмкин: КФҮгә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнсә;

10) мунципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматның яки документның булмавын яки дөрес булмавын әйтмичә, документларны кабул итүдән, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартып (210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш), муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән ул мәгълүматны һәм документларны таләп итү

Әлеге очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү түбәндәге шартларда мөмкин: КФҮгә тиешле муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә күрсәтү функциясе йөкләнсә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язма формада яки электрон формада Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яки КФҮне оештырган дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына, алга таба - КФҮ гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә.

Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советына тапшырыла.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге КФҮ җитәкчесенә тапшырыла.

КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ гамәлгә куючыга яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 өлешедә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен кулланып, КФҮ аша, http://bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының рәсми порталы аша, http://uslugi.tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталына, http://gosuslugi.ru адресы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләре) порталы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүче шикаятьне шәхси кабул итү вакытында тапшыра ала.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүче аны шәхси кабул итү вакытында тапшырырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларныц җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләре исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә

юридик зат булган мөрәҗәгать итүченең исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап җибәрелергә тиеш почта адресы;

3) Башкарма комитетның, вазыйфаи затның яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар.

4) мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетның, вазыйфаи затның яисә Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәүне ачыклаучы дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче дәлилләрен раслаучы документларны (булганда) яки аларның күчермәләре тапшырырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәп бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.4. Шикаять мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкаләтлесе тарафыннан имзалана.

5.5. Шикаятьне карау срогы – теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә.

Башкарма комитет, күп функцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять бирелгән очракта яки мондый төзәтүләрне кертү срогын бозу турында шикаять бирелгәндә - аны теркәү көненнән соң биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәсе буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләү Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Баулы муниципаль районының муниципаль хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаять канәгатьләндерелми.

5.7. Регламенттның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма формада һәм, мөрәҗәгать итүченең теләге булса, электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылганда, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән җавапта муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, КФҮ яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында тормышка ашырган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенү сүзләре языла һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәтне алу өчен нишләргә кирәклеге турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, Башкарма комитет җитәкчесе ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм булдырмау максатларында чаралар билгели.

5.11. Шикаятьне карау барышында яисә тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров